# Халык хәтере – мәңгелек!

**Максат**: яшь буында сугыш һәм тыл ветераннарына карата хөрмәт хисе,Ватанны ярату хисләре тәрбияләү; Бөек Ватан сугышы каһарманнары алдында баш ию,батырлыкларын олылау;патриотизм хисләре тәрбияләү.

**Бизәлеш**:уздырылачак зал шарлар,гөлләр белән бизәлә,"Бөек Җиңүгә-78 ел"дип язылган плакат,фронтавик шагыйрьләрнең,язучыларның әсәрләреннән "Үткән сугыш безнең хәтердә"күргәзмәсе альбомнар,стендлар куела.

**Кичә барышы**.

Акрын гына "Тормыш җыры"(М.Әмир сүзләре,Җ.Фәйзи музыкасы)көе уйнала.Ә сәхнәдә бер төркем кешеләр уйнап, сөйләшә-сөйләшә урак уралар,печән өемнәре ясыйлар,сәхнә шау итеп тора.Шул вакыт сәхнәгә бер егет йөгереп керә.

**Егет:**Кызлар,егетләр кайгы...кайгы(хәлсерәгән),ил өстенә фашистлар бәреп кергән,илне сакларга кирәк,сугыш башланган.Безнең илнең чикләрен бозып, бәреп кергәннәр.

(Шау-гөр киләләр,елыйлар,Левитан тавышы фонограммасы,авылга йөгерәләр).Сәхнәдә ярым караңгылык,талгын гына көй уйный.

**А.б**.1941 елның 22 июнь таңы туып кына килә иде әле.Илебезнең көнбатыш чикләренә кара тәреле дәһшәтле танклары үрмәләде,болыт төсле ябырылып очкан самолетлар шәһәрләребез өстенә бомбалар яудыра башлады.Сугыш ялкыны дөрләде.Миллионнарча кеше,ир-егетләр,хәтта хатын - кызлар,кулларына корал алып фашизмга каршы көрәшкә күтәрелде.

(Сәхнәдә егетләрне кызлар елап сугышка озаталар,слайд эшләнә,анда сугышка китү,аларны озату,вагоннарга төялеп китү күренешләре күрсәтелә , сәхнә алдында солдат киеменнән егет һәм кыз шигырь укыйлар).

**Егет**:Соңгы тапкыр кичә көлде дөнья,

Соңгы тапкыр кояш балкыды.

Таң атмады бүген,таң атмады,-

Алды җирне сугыш ялкыны.

**Кыз**:Ирләр китте,кызлар елап калды,

Шаулап калды иген өлгереп.

Басу капкасына кадәр озата барды

Яше-карты барсы өзелеп.

**Егет**:Ватан куркыныч астында,

Кылыч ал мәгърур халык!

Туган ил безне чакыра

Яшәсен җирдә халык.

Кыз:Явыз дошман килә ил өстенә,

Ил байлыгын талап җыярга.

Алып килә канлы палачларын,

Халкыбызның канын коярга.

**Егет**:Юлбасарлар таптый җиребезне,

Ватан сугышына мин китәм:

Менә-балам.Син әнкәсе аның

Балабызны тотып ант итәм:

Синең өчен,туган ил өчен,

Мылтык тотып баскан җиремнән

Бер адым да артка чигенмәм!

(“Солдатлар” җырының ике куплеты башкарыла Р.Әхмәтҗан сүзләре,Ф.Әхмәдиев көе;Әмирхан Еникинең “Кем җырлады”әсәреннән өзек сәхнәләштере -лә.)

**Автор:**Ватан сугышының дәһшәтле көннәренең берсе иде.Күзгә караңгы төн дә кечкенә генә җимерек станциядә ике эшелон очрашып,янәшә туктадылар ...Теплушкаларның берсендә түбәндәге сәкедә яралы лейтенант ята.
Егет кара янып кипкән иреннәрен хәлсез ялап куйды.Эчәсе,бик эчәсе килә иде аның.

**Шәфкать туташы**:Хәзер,хәзер,лейтенант.Түз,түз.
(Алюминий кружка белән бер йотым су эчерә.Егет керфекләрен селкетә.)
Сәхнә артында татарча җыр яңгырый.
**Автор**:Егетнең колагына каяндыр җыр ишетелде.Бу җыр аны ут эчендә яткан җиреннән сак кына күтәреп,каядыр еракка,татлы хыял дөньясына алып менеп китте.**Лейтенант**:Татарча җыр!...Нәрсә ишетәм мин,кемне ишетәм мин?...Минем Таһирәм җырлый түгелме соң?Шул ич,шул,Таһирә тавышы.Кайда ул?(Егетнең башы мендәр читенә авып төшә.Шәфкать туташы пульс тикшерә,башына салкын чүрәк куя.)
**Шәфкать туташы**:Ни булды сиңа?Ни булды?
**Автор**:Әмма егет хушыннан язмады,һичнәрсәне,һичкемне сизмәс булсада җырны ишетүдән туктамады.Җыр янәшәдәге эшелонның бер вагоныннан килә иде.Әгәр теплушка белән вагонның ишекләре бер-берсенә туры килгән булсалар,җырлап торучы кыз үзе дә күренгән булыр иде.(Егет ыңгыраша,шәфкать туташы ярдәм күрсәтә.) “**Ком бураны” кое яңгырый**.(Ә.Фәйзи музыкасы,татар халык көе.) Егет инде җырны моң итеп кенә ишетмичә,гәҗәеп ачык сүрәтләр тезмәсе итеп күрә иде.
Музыка астында Таһирә белән егетнең аерылышу вакыты бара.
**Егет**:Кайчан соң мин кабат синең
Моңсу күзләреңне күрермен
Кайчан соң мин кабат синең
Назлы көлүеңне ишетермен?
Ник дәшмисең,әйт бер сүз булса да
Ут эченә китә барыбыз да.

**Кыз**:Нигә әйттең миңа сөю сүзен
Күптән көткән айлы тын кичтә?
Инде хәзер аерылабыз дисең
Синсез калган йөрәгем соң нишләр?
Мәхәббәт ул бүленмәскә тиеш!
Ярату ул була үлемсез.
Мәхәббәт бербөтен булырга тиеш,
Сугыш безне аермас,күрерсең!
**Егет:**Мин бик тиздән кайтырга дип китәм,
Телә бары җиңү килүен.
Дошманнарны җиңеп,сау кайтырга
Ярдәм итәр сине сөюем.
**Кыз**:Мин ышанам.Тиздән очрашырбыз.
Кабатланыр айлы тын кичләр.
Яу кырында исән-сау йөрергә
Ярдәм итәр минем саф хисләр. **Автор**:Кыз җырлавыннан кайчан туктады,каршыдагы эшелон тавышсыз-тынсыз гына кузгалып китте,егет моны сизмәде.Ул инде яңадан аңына килә алмады.

**Җыр:"Җиңеп кайт".(**К.Нәҗми сүзләре,З.Хәбибуллин көе)
**Ф.Кәрим"Кыңгыраулы яшел гармун"**(укый Э. Сәләхетдинова).

(Сәхнәдә ут сүнеп ала.Авыл халкы кабат эштә,бер аягын аксатып бригадир керә,шул вакыт радио тавышы ишетелә,радиодан Левитан сугыш тәмамланганы хакында хәбәр итә.Халык шау-гөркилә,кочаклаша,елаша,шатлана.Сәхнә алдында җыр җырлана.)

**Җыр:"Кайту**"(Марсель Галиев сүзләре,Луиза Батыр – Болгари көе.)

**А.Б**.Сугыш...Ничә миллион кешенең гомерен өзгән,купме баланы ятим,ана – ларны тол калдырган.Меңләгән шәһәрләр җимерелгән,җир йөзеннән гөрләп торган авыллар юкка чыккан,шау чәчәккә күмелгән бакчалар кара күмергә әйләнгән.

**А.б.**Йөрәкләрдән мәңге китмәс инде
Утлы еллар поход юллары

Туган якка кире кайтмадылар
Һәр авылның күпме уллары
Ябь-яшь килеш алар мәхрүм калды
Бу тормышның барлык назыннан
Исемнәре һәйкәл күкрәгенә
Авыл саен тезеп язылган.
Чал аналар көтә юлга карап
Алар һаман өмет өзмәгән
Авыл саен, һәрбер йорты саен
Кайтмый калды ничә йөзләгән.

**А.б.**Безнең Яңгул җирлегеннән 575 кеше яу кырына киткән. Кызганыч, күпме авылдашларыбыз туган туфракларын күрә алмадылар алмадылар, чит җирләр дә еракта калдылар. Яңгул һәм Иске Көшкәт авыллары буенча алар 275. Туган җирләре өчен башларын салган бу батырларны безнең онытырга хакыбыз юк.(Сәхнәдә һәйкәл булып солдат чыгып баса).

Хөрмәтле кунаклар, балалар! Безнең якты киләчәгебез, сабыйларның тыныч йокысы өчен башларын салган авылдашларыбызны зур хөрмәт белән искә алыйк.

## ***1 минутлык тынлык.***

Туган җирләрдән еракта башларын салган авылдашларыбызның якты истәлеге күңелләрдә мәңге сакланыр. Алар хөрмәтенә салынган һәйкәл моның ачык мисалы.

**1**
Авылыбызның иң-иң уртасында,
Иң матур һәм калку урында.
Һәйкәл булып солдат басып тора,
Винтовкасын кысып кулында.

**2.**
Иңенә салган плащ-палаткасы
Кире кага салкын җилләрне.
Кисәтүле караш бөркеп тора,
Кырыс, җитди, уйчан күзләре.

**3.**
Әйтә кебек алар: Тукта, иптәш!
Тыныч кына үтеп китмә син.
Мин бит гади бер сын гына түгел,

Мин – көрәшче. Авылдашың синең,
Иптәшең...

8.
Без киләбез сиңа буранлы кышларда,
Киләбез сиңа тынычлыкны саклап.
Син- безнең абый,
Син – безнең әти,
Син – безнең бабай, Билгесез Солдат!

**9.**
Без киләбез сиңа кояшлы җәйләрдә,
Бөек нәселнең дәвамын раслап.
Син - безнең абый,
Син - безнең әти,
Син - безнең бабай, Билгесез Солдат!

*(венок салалар).*

**Таякка таянган, кулына чәчәк тоткан ана боек кына һәйкәл янына килә:**

Исәнме, улым, менә мин яңадан синең янында, салкын түгелме, балакаем?

**Улы:**

Юк, әнкәем, салкынның ни икәнен белмим мин. Миңа беркайчан да салкын булганы юк.

**Ана:** Нигә үзеңне сакламадың, улым? Хәтерлисеңме, җиңәребез дә, кайтырбыз дигән идең, улым?

**Улы:** Әйткән сүзләрем һәрвакыт йөрәк түрендә, әнкәем. Мин генә тугел, меңнәр, милионнар бу көрәштә башларын салды. Картлык көнендә ничек яшисең, әнкәй?

**Ана:** Бар да җитеш, улым. Менә әби инде мин. Бәлки бик тиз генә танымагансыңдыр?

**Улы:** Таныдым, әнкәем, әллә кайлардан таныдым, күз нурым. Әгәр мөмкин булса, мин сине кочагыма алыр идем.

Сугыш фаҗигасен онытмасын еллар,
Язмышлары миндәй-миллионнар.
Барысын илгә бирдем-күпме көчем булды,
Һәлак булуым да илем өчен булды.
Кичер, әнкәй мине, кичер, әнкәй, кичер,
Яу кырыннан кайта алмавымны.
Кичер, әнкәй, кичер, чит ил туфрагында

Мәңгелеккә ятып калганымны.

**Аначәчәк сала, яшен сөртә, акрын гына атлап чыгып китә.**

**А.б.** Сугыштан туган ягыбызга 182 кеше әйләнеп кайта. Ләкин ветераннарыбызның саны елдан-ел кими. Бүгенге көндә авылыбызда сугыш ачысын үз җилкәсендә татыган, бердәнбер ветеранныбыз, Хәкимова Разия апа гына яши. Әйдәгез Разия апабыз хөрмәтенә җыр тапшырыйк әле.

**<u>Җыр:”Бәйрәм безнең урамда”(С.Урайский сүзләре,М.Мозаффаров көе).</u>**

**А.б**.Бөек Ватан сугышында ир-егеткә иңдәш булды
Сылу, гүзәл хатын-кызлар
Зур җиңүгә өлеш керткән,
Ил тарихын нурлы иткән,
Сүнмәс кояш, ай-йолдызлар

Кулына корал алып илебезнең азатлыгы өчен көрәшүчеләр сафына гүзәл затларыбыз хатын-кызларыбыз: Разыя Хәкимова,Әминә Сафиуллина, Җиһан Мөхәммәтгалиевалар да баса. Без бүгенге көндә Әминә һәм Җиһан апалар безнең арабызда юк. Әлеге көчле рухлы хатын-кызларыбыз истәлегенә җыр тапшырабыз.

**<u>Җыр:”Ана сагышы”(А.Игебаев сүзләре,К.Әһлиуллин музыкасы)</u>**

**А.б**.Якташларыбыз сугышның төрле фронтларында дошманга каршы аяусыз сугышның, тиңдәшсез батырлыклар күрсәткән, сугышның иң кайнар нокталарында булган, Берлинга кадәр барып җитеп, Җиңүгә зур өлеш керткән. Алар арасында авылдашыбыз Советлар Союзы Герое Габдулла Гарифуллин, Невский ордены кавалеры очучы Хәйретдин Җамалиев, Бөек Ватан сугышы партизаны медале кавалеры Газизулла Исмәгыйлов, татар әдәбиятенең өметле киләчәге булып саналган яшь шагыйрь Хәбра Рахман һәм башкалар да бар.

**А.б**.Дан җырлыйк без бу буынга,
Дан җырлыйк батырларга.
Яңгыратып шәһәр,авылга,
Урманга,кырларга.

Хәзер җырланачак әлеге батырларыбыз рухына дога булып барып ирешсен иде.

**Җыр: "Габдулла батыр турында җыр"(М.Галиев сүзләре,Ә.Сабиров музыкасы.)**

**А.б**.Ул елларны ничек онытасың,
Ил язмышы кылыч йөзендә.
Ир-егетләр китте яу кырына
Алып көче тоеп үзендә.
Ирләр китте,кызлар елап калды,
Шаулап калды иген өлгереп.
Басу капкасына кадәр озата барды
Яше –карты барсы өзелеп.
Ирләр китте,кызлар елап калды,
Елап калды күпме хатыннар.
Туйда кигән күлмәкләре калды,
Күпме бала калды,ятимнәр.

**А.б** Әйе, авылда картлар, хатын-кызлар, балалар гына калды. Ә тормышны алып барырга-иген игәргә, балаларны да ач, ялангач итмәскә, сугышка төрле җылы киемнәр дә әзерләп җибәрергә, гомер буе бетмәс тоелган налогын да илтеп түләргә кирәк иде. Ирләре, уллары, туганнары яу кырында батырлык-лар күрсәткәндә, тылдагы хатын-кызларыбыз үзләрен аямыйча эшләде,чөнки җиңү теләге көчле иде. Рәхмәт Сезгә!

**Җыр:"Әйләнеп кайтыгыз."**

**А.б.** Чабатадан,тездән суга батып
Язгы чәчү җитәр алдыннан,
Чыгып киткән икән симәнәгә
Хатын-кызлар безнең авылдан.
Сыерлары юлда батып калган,
Җилкәләргә күчкән симәнә
Бу турыда бүген сөйләгәндә
Әнкәй һаман елап җибәрә.
40-50 чакырым язгы суда-
Кайта алмасаң илең ач кала.
Хатыннарда тик бер хәсрәт-
Һәр йорт саен көтә ач бала.

Без сугыш афәтен үз иңнәрендә күтәргән фронтовиклар алдында, үз-үзен аямыйча фронтны бертуктаусыз корал, азык-төлек, кием-салым белән тәэмин иткән тыл хезмәтчәннәре алдында баш иябез. Батырларның исеме тарихта Хөрмәтле кунаклар, балалар! Безнең якты киләчәгебез, сабыйларның тыныч

йокысы өчен башларын салган авылдашларыбызны зур хөрмәт белән искә алыйк.

**Тыл батырлары хөрмәтенә җыр”Уракчы кыз”(Н.Исәнбәт сүзләре,Х.Ибрахимов музыкасы).**

**А.б**.Әтиләрнең сугышып йөргән чагы,
Безнең яңа туган ел булган.
Капчык аскан егермеләп хатын
Басуларга кайтып егылган.
Тәпи йөрер йөрмәс бала-чага
Буразнадан билчән утаган.
Илгә- икмәк, авыл үзе өчен
Көлчә салган алабутадан.
Бер бәләкәй көлтә ега алган
Ул чорларның нужа хуҗасын.
Олылар күк күтәргән бит шулар,
Ил хәсрәтен,Ватан нужасын.

Балачагын, яшьлекләрен сугыш урлаган авылдашлар! Сезнең сабый чагыгыз шушы авыр, рәхимсез сугыш чорына туры килгән. Бүген безнең балаларыбыз күргән рәхәтлекләр сезгә тимәгән, сез бары тик ачлык, ялангачлык шаһите генә булгансыз. Шуңа күрә сезгә хәзерге көндә рәхәт, тыныч картлык кичерергә язсын.

А.б.Балачагын сугыш йоткан буын,
Кырыс язмыш сезне сөймәде.
Күпләрегез әтиләре биргән
Солдат пилоткасын киմәде...

Сезнең күңел һаман китек инде,
Бәсләр иртә сарган апа-агайлар.
Әтиләрен эзләп китеп бара
Җитмеш яше тулган кызлар-малайлар.

Хәзер сезнең хөрмәткә җыр тапшырабыз. **Җыр:”Сагыну балладысы”(Г.Хуҗиев,С.Садыйкова музыкасы).**

**А.б**.Офыкларга тулды кара төтен,
Төсен алды төтен далаларның.
Елга булып яше җиргә сеңде
Сугыш чорындагы балаларның.

**А.б**. Ил хәсрәте ирләр иңсәсендә,
Ат чыдамый торган авыр хезмәт.
Алтмыш тулмый җиргә иңә ирләр,
Илгә рәнҗеп, күрми кадер-хөрмәт.

**А.б.** Хәтер төпләрендә ачы язмыш,
Сөрән сала авыл, калаларга.
Уйчан йөзләр,әле дә моңсу күзләр
Сугыш чорындагы балаларда.

**А.б.** Яшьлекләре ут эчендә калды
Гомер буе моңлы кызларның.
Бәхетләрен сугыш урлаганда,
Башкаларның күңеле сызармы?

**А.б.** Яуда ятып калды алар өчен
Яр буласы асыл егетләр.
Сугыш белән бергә киселде лә,
Өзелде шул якты өметләр.

**А.б**.Хөрмәтле ветераныбыз Разия апа,тыл ветераннары,сугыш чоры балала – ры! Бүгенге көндә сезгә балаларыгыз, оныкларыгыз хөрмәтендәрәхәт яшәргә язсын.

**Җыр:”Ана җыры”(Ш.Маннур сүзләре,Ә.Бакиров музыкасы).**

**А.б.**Әгәр дә сез иртә белән ефәк яфраклы гөлләрнең чәчәк атуын күрәсез икән, шул иртәдә өй каршыгындагы тирәктә кошлар сайравын ишетәсез икән, белегез-бу иртәнге шатлыкта сугышта үлеп калганнарның ялкынлы тормышы бар. Әгәр дә таң җилләре битләрегездән иркәли икән, белегез – ул җилләрдә сугыштан кайтмаган бабаларыгыз, әтиләрегез турында тирән сагыш бар.

Әгәр сез тыныч, матур өйләрдә, тату гаиләдә яшисез икән, белегез-бу җирдә сезнең матур яшәвегез өчен меңләгән солдатның каны, әби-бабаларыбызның ачы тире тугелгән. Бу гомернең кадерен, тормышның ямен белеп яшәгез !

<u>**Җыр: “Бәхеттә-шатлыкта.”(Н.Яппарова сүз. Н. Шәймәрдәнов көе.)**</u>

## Файдаланган әдәбият:


1.Ф.Кәрим т.1 .Әсәрләр.Казан тат.китап нәшрияты.

2.Җырлар китабы.Казан тат.китап нәшрияты.

3.Ә.Еники.Сайланма әсәрләр т.1.Казан тат.китап нәшрияты.

4.Ачык дәрес,2012 ел ,май.

5.Ә.Фәйзи.Шигырьләр һәм поэмалар.т.1 .Казан тат.китап нәшрияты.

6.М.Әмир.Әсәрләр. т.2.Казан тат.китап нәшрияты.